**СОВЕТ КУРКАЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, п.ж.д.рзд. Куркачи, ул. Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык тимер юл разъезды бистәсе, Гагарин урамы, 7

Тел./факс 8(84365) 71-2-15, e-mail:Kurk.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**29 март 2021 ел** **№ 21**

**Советның 2019 елның 2 июлендәге 127 нче номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Коркачык авыл җирлеге Советының 2019 елның 2 июлендәге 127 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәнең (Советның 13.08.2019 № 130, 10.09.2020 № 162 карары редакциясендә) 3 бүлегенең 3.3. пунктына түбәндәге эчтәлекле 17 пункт белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

«17) алкогольле, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Салихҗанов